# КАРАР

**2022 елның 22 ноябре** **№ 2**

**Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Югары Юмья авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 22 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Ошторма-Юмья авыл җирлеге Югары Юмья авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Югары Юмья авылының Тимер юл, Май, Тау асты урамнарында юлларны төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту, вак таш җәю (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, су торбаларын урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Югары Юмья авылында янгын гидрантлары, янгын рукавлары, стволлар, переходниклар, колонкалар, мотопомпа сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәләгә ашыру;
- чишмәләрне төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Югары Юмья авылында суүткәргеч челтәрләрне һәм су белән тәэмин итү системаларын, су башнясын (ВНБ) ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, грунтны кул һәм экскаватор белән эшкәртү, торба үткәргеч урнаштыру, ремонтлау, бетон боҗралар, капкачлар һәм люклар, су башнясы өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, (материаллар сатып алу, экскаватор һәм манипулятор хезмәтләре өчен түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);
- Югары Юмья авылының урам юл челтәрен карап тоту (кышын юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу, төзекләндерү; трактор һәм чапкыч

өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- урам яктырткычлары сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Югары Юмья авылы зираты территориясен карап тоту, ремонтлау, төзекләндерү һәм зират коймасы урнаштыру, күмү йортын төзү, урнаштыру, ремонтлау, чүп контейнерлары, мотокослар, бензин пычкылары, генератор һәм инвентарь (көрәкләр, тырмалар, ломнар, баскычлар) сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- видеокамера сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)?

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

2022 елның 22 ноябренә торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны – 180 кеше.

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 145 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 95.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 95 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге Югары Юмья авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Признать решение по вопросу: «Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Ошторма-Юмья авыл җирлеге Югары Юмья авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:
- Югары Юмья авылының Тимер юл, Майс, Тау буе урамнарын ремонтлау, төзекләндерү, вак таш җәю (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Югары Юмья авылында янгын гидрантлары, янгын рукавлары, стволлар, переходниклар, колонкалар, мотопомпа сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета

документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәләгә ашыру;
- чишмәләрне төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Югары Юмья авылында суүткәргеч челтәрләрне һәм су белән тәэмин итү системаларын, су башнясын (ВНБ) ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, грунтны кул һәм экскаватор белән эшкәртү, торба үткәргеч урнаштыру, ремонтлау, бетон бокралар, капкачлар һәм люклар, су башнясы өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, (материаллар сатып алу, экскаватор һәм манипулятор хезмәтләре өчен түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);
- Югары Юмья авылының урам юл челтәрен карап тоту (кышын юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу, төзекләндерү; трактор һәм чапкыч өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- урам яктырткычлары сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Югары Юмья авылы зираты территориясен карап тоту, ремонтлау, төзекләндерү һәм зират коймасы урнаштыру, күмү йортын төзү, урнаштыру, ремонтлау, чүп контейнерлары, мотокослар, бензин пычкылары, генератор һәм инвентарь (көрәкләр, тырмалар, ломнар, баскычлар) сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- видеокүзәтү системасы сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);
- физик культура һәм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, төзекләндерү, спорт, уен җиһазлары һәм инвентарьлар сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Ошторма-Юмья авыл җирлеге башлыгы: С.В. Тимофеев